ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасында яшәү минимумы турында»;**

2) преамбулада «Татарстан Республикасында» сүзләрен төшереп калдырырга, «тормыш дәрәҗәсен күтәрү гамәлләрен башкарганда» сүзләрен «социаль программаларны эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы халкының тормыш дәрәҗәсен бәяләү, кирәкле дәүләт социаль ярдәме күрсәтү һәм аз керемле гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү, Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру һәм федераль законда билгеләнгән башка максатлар өчен» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяда:
а) икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«яшәү минимумы – граждан керемнәренең тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле минималь суммасы;»;

4) 2 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләме «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда билгеләнә.»;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга, «квартал саен» сүзләрен «ел саен» сүзләренә алмаштырырга;

5) 3 статьяда «квартал саен» сүзләрен «ел саен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 05 апрель
№ 15-ТРЗ